2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авылы җирлеге Шарлама авылы гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

7 декабрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең Шарлама авылы гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең Шарлама авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү системасын, су башняларын, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган скважиналарны һәм башка инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау, смета төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Сөләй авылы, Совет урамы, 53А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сөләй авыл җирлеге башлыгы А.З.Бикбаев